| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ВЕРХНЕСЕРДИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ |
| --- | --- | --- |

422015 Республика Татарстан Атнинский район с. Верхняя Серда, д.21
Тел./факс: (88-43-69) 3-28-70 E-mail: Vserd.Atn@tatar.ru

**КАРАР**

**«01» ноябрь 2025 ел** **№2**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлегенең Югары Сәрдә торак пунктында халык җыенын билгеләү һәм халыкның үзара салым акчаларын керту һәм куллану мәсьәләсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әтнә муниципаль районының Югары Сәрде авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Халыкның үзара салым акчаларын керту һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын 2025 елның 13 ноябренә билгеләргә
1.1. Билгеләргә:
- халык җыенын оештыручы һәм халыкның үзара салым акчаларын керту һәм куллану мәсьәләсе буенча -Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югары Сәрде авыл җирлеге башкарма комитетын;
- халык җыенын үткәрү вакыты-2025 елның 13 ноябре, 15.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны-Югары Сәрдә авылы, Үзәк ур., зд.21
1.2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрде авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:
- 2025 елның 10 ноябреннән дә соңга калмыйча халыкга Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Югары Сәрдә авыл җирлеге башкарма комитетында түбәндәге адрес буенча халык җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Югары Сәрдә авылы, Үзәк урамы, зд. 21;
- Югары Сәрдә торак пунктында сайлау хокукына ия яшәүчеләрнең исемлекләрен төзергә;
- халык җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Югары Сәрдә торак пункты халкына халык җыены турында мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

1.3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниеипаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны

буенча теркәлгән һәр баликъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк граңданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, мәхсус хәрби операциядә һәләк булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әхәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы территориясен чистарту (агачларны һәм куакларны кисү, үләнне чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы зираты территориясен чистарту (агач һәм куакларны кисү, үләннәрне чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен скважина бораулау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); су җыю җайланмалары сатып алу))

4) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары Сәрдә авылының Алмаш, Тургай, Яшеллек урамнарындагы урам юлларын ремонтлау (вак таш сатып алу һәм салу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://atnya.tatarstan.ru һәм ТР, Әтнә муниципаль районы, Югары Сәрдә авылы, Үзәк ур., зд.21. адресы буенча уршашкан информацион стендка куярга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Р. Р. Хөснетдинов